**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

2023 елның 05 апреле №12 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 14.03.2022 ел, №58-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Территорияне планлаштыру документларын, шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында» 2022 елның 02 апрелендәге 575 номерлы карары, 2023 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» 28.02.2023 ел, № 14 карары белән, 2023 елның 30 мартындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Ютазы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 30 мартыннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының экология һәм җирдән файдалану буенча даими

комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин